ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.06.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1802**

Зеленодольск муниципаль районының 2017/2018 елгы ягып җылыту сезонына әзерлекне тикшерү муниципаль программасын раслау турында

Федераль законның 2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190- ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы «Ягып җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 103 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының 2017/2018 елгы ягып җылыту сезонына әзерлекне тикшерү муниципаль программасын, кушымтада каралганча, расларга.
2. 2017/2018 елгы ягып җылыту сезонына җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның әзерлеген тикшерү буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 24 июнендәге
1802 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының ягып җылыту сезонына әзерлекне тикшерүнең**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

## 1. Норматив-хокукый документлар.

1. Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы Федераль законы.
2. РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы«Ягып җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 103 номерлы боерыгы.
3. РФ Энергетика министрлыгының 2003 елның 24 мартындагы 115 номерлы боерыгы белән расланган җылылык энергиясен техник эксплуатацияләү кагыйдәләре.

## 2. Гомуми нигезләмәләр.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларының ышанычлы эшләвен тәэмин итү, кулланучыларның өзлексез җылылык, су, электр, газ һәм ягулык белән тәэмин итүгә ирешү, энергия чыганакларының кирәкле параметрларын тоту һәм биналарда норматив температура режимын тәэмин итү максатларында,ягып җылыту чорына үз вакытында һәм һәрьяклап әзерләнү, торак-коммуналь хезмәтләрдән файдаланучыларның кулланышын һәм түләү дисциплинасын исәпкә алып, җирле үзидарә органнарының, торак-коммуналь хуҗалык оешмаларының мөһим бурычы булып тора.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын ягып җылыту чорына әзерләү, алар эшенә температура һәм башка һава торышы факторларының йогынтысын булдырмау, нормадан тыш тузуны һәм сафтан чыгуны кисәтү, шулай ук халыкның тормыш эшчәнлеге шартларын һәм коммуналь инфраструктура һәм биналардагы инженер-техник тәэмин итү системаларының эшләү режимнарын тәэмин итү максатыннан алып барыла.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылыту чорына әзерләү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- торак-коммуналь хуҗалык объектларын норматив техник файдалануны, биналарда билгеләнгән температура режимын саклауны, халыкның яшәү санитария-гигиена шартларын үтәүне;
- торак-коммуналь хуҗалык объектларының максималь ышанычлылыгын һәм экономияле булуын;
- торак фонды һәм социаль өлкә биналарының, коммуналь корылмалар җиһазларының, инженер-техник тәэмин итү системаларының һәм төзелеш конструкцияләре хезмәтенең норматив сроклары үтәлүен;

-матди-техник чараларны һәм ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны.

Торак-коммуналь хуҗалык объектларын җылыту чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү эшләре түбәндәгеләр белән ирешелә:
-вазифаи затлар тарафыннан федераль һәм республика законнарын, муниципаль норматив хокукый актларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен, җитәкчелек һәм инструкцияләр таләпләрен үтәүләре белән;
-төзелеш, капиталь һәм агымдагы ремонт планнары, шулай ук торак - коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү буенча проект-смета документларын эшләү һәм үтәү белән;
- техник торышны, план-кисәтү тикшерүләрнең барлык төрләрен үткәрүне даими контрольдә тотуны, шулай ук аварияләр һәм төзексезлекләр килеп чыгу сәбәпләрен җентекләп анализлау һәм ремонт-торгызу эшләренең тиешле күләмен билгеләү белән;
-ремонт-торгызу һәм көйләү эшләрен билгеләнгән срокта һәм таләп ителгән сыйфатлы, бурычлар куюның һәм ремонт-торгызу эшләренә йомгак ясауның нәтиҗәле системасы булган төгәл оештыру һәм башкару белән;
-торак-коммуналь хуҗалык оешмаларын әзерләнгән эксплуатацион һәм эксплуатацион-ремонт персоналы белән , йөкләнә торган бурычларны хәл итүне тәэмин итәрлек дәрәҗәдә комплектлау белән ;
-ремонт-торгызу эшләрен матди-техник тәэмин итү, эксплуатация кирәк-яракларына кирәкле максатчан финанслау бүлеп бирү, фондны капиталь һәм агымдагы ремонтлау, матди ресурслардан рациональ файдалану белән;
-ягып җылыту чоры башланыр алдыннан тулы күләмдә оештыру-техник чаралар , җиһазларның эшләвенә сынаулар һәм тикшерүләр комплексын башкару белән.

## 3. Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия эше.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәгеләрне оештыра:

– җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык пунктларының,җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягып җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

– торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә объектларының ягып җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча комиссия эшен;

– торак фондының җылылык кабул итүгә ,коммуналь корылмаларның ягып җылыту чорына әзерлеген тикшерүне, коммуналь объектларның һәм авария бригадаларының дежур сменалары әзерлекле һәм аттестацияләнгән персонал белән тупланганлыгы, аларны авария хәле очрагына МТР запасы, ягулык һәм химик реагентлар белән тәэмин ителгәнлеген.

Җылылык белән тәэмин итү чыганакларының, үзәк җылылык

пунктларының, җылылык челтәрләренең һәм гомумән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягып җылыту чорына әзерлегенә бәя 15 нче сентябрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Тикшерү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган комиссия тарафыннан башкарыла.

Комиссия эше ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү графигына туры китереп башкарыла (1 нче таблица)

1 нче таблица

**Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү графигы**

| № т/б | Тикшерелергә тиешле объектлар | Объектлар саны | Тикшерү үткәрү срогы | Тикшерү барышында тикшерелгән документлар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары. | 103 | 01.08.2017-15.09.2017 | 3 нче кушымта нигезендә |
| 2 | Балалар учреждениеләре | 54 | | 4 нче кушымта нигезендә |
| 3 | Уку учреждениеләре | 46 | | |
| 4 | Мәдәният учреждениеләре | 58 | | |
| 5 | Сәламәтлек саклау учреждениеләре | 80 | | |
| 6 | Торак фонды | 1043 | | |

Комиссия тарафыннан 2017/2018 елгы ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү программасының (алга таба - Программа) 3, 4 нче кушымталарында билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше тикшерелә.

Җылылык челтәре һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның РФ Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган Ягып җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре белән (алга таба Кагыйдәләр) билгеләнгән таләпләрне үтәвен тикшерү, техник регламентлар һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәү предметына, комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тикшерү үткәрү максатларында, комиссия әзерлек буенча таләпләрнең үтәлешен раслый торган документларны карый, ә кирәк булганда - тикшерү объектларын карап тикшерә.

Тикшерү нәтиҗәләре ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү акты (алга таба - акт) белән рәсмиләштерелә, ул тикшерү тәмамланганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча, әлеге Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителә торган үрнәк буенча төзелә.

Акт, тикшерү йомгаклары буенча , комиссиянең түбәндәге нәтиҗәләрен үз эченә ала:

– тикшерү объекты ягып җылыту чорына әзер;

– тикшерү объекты, билгеләнгән срокта комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә карата җитешсезлекләрне бетерү шарты белән, ягып җылыту чорына әзер булачак;

– тикшерү объекты җылылык чорына әзер түгел.

Комиссиянең әзерлек таләпләрен үтәүгә карата шелтәләре булса яки актка әзерлек таләпләрен үтәмәгән очракта, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, шелтәләр исемлеге (алга таба - Исемлек) теркәлә.

Ягып җылыту чорына әзерлек паспорты (алга таба - паспорт) әлеге Программага 2 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителә торган үрнәк буенча төзелә һәм, тикшерү объекты җылыту чорына әзер булган очракта, шулай ук комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә карата шелтәләр Исемлектә билгеләнгән срокта бетерелгән очракта, комиссия тарафыннан бирелә.

Паспортларны бирү вакыты 15 сентябрьдән дә соңга калмыйча - җылылык энергиясен кулланучылар өчен, 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча - җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары өчен, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекләр өчен билгеләнә.

Әлеге Программаның 1 нче таблицасында билгеләнгән срокларда әзерлек буенча таләпләрне үтәү (үтәмәү) таләпләрен үтәүгә карата күрсәтелгән шелтәләрне бетергән очракта, комиссия кабат тикшерү үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча яңа акт төзелә.

Тикшерү объектлары буенча әзерлек паспорты алмаган оешма ягып җылыту чорына әзерлекне дәвам итәргә һәм әзерлек таләпләрен үтәү (үтәлмәү) буенча акттагы Исемлектә күрсәтелгән шелтәләрне бетерергә тиеш. Комиссиягә әзерлек буенча таләпләрне үтәүгә (үтәлмәүгә) шелтәләрне бетерү турында хәбәр иткәннән соң кабат тикшерү башкарыла. Комиссиянең уңай бәяләмәсендә, ягып җылыту чорына әзерлек турында нәтиҗә ясап, кабат акт рәсмиләштерелә, әмма агымдагы ягып җылыту чорында паспорт бирмичә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 24 июнендәге
1802 номерлы карарының
1 нче кушымтасына
1нче кушымта

**Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү акты 20_/20-_ ел**

________________________ «___»___________20__ ел
(акт төзү урыны)

____________________________________________________ оешкан Комиссия
(документ формасы һәм төзелгән комиссиянең реквизитлары)

«___»___________20__ _____________________________расланган ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү программасы нигезендә

____________________________________________________________________

(Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерүче орган җитәкчесенең исем-фамилиясе)
«___»__________ 20__елдан «___»____________ 20__елга кадәр «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27 июль, 2010 ел, № 190-ФЗ Федераль закон нигезендә, ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү үткәрде ____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

(җылыту сезонына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муниципаль берәмлекнең, җылылык белән тәэмин итүче оешманың, җылылык челтәре оешмасының, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)
Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү түбәндәге объектларга карата үткәрелгән:
1.______________________________
2.______________________________
3.______________________________

Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү барышында комиссия түбәндәгеләрне билгеләде:____________________________________________________________________ _

(ягып җылыту чорында эшләргә әзер/әзер түгел)
Тапшырылган документлар нигезендә ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия нәтиҗәсе: ____________________________________________________________________

Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү актына кушымта _ / _ _ ел

Комиссия рәисе: ____________________________________________________

Комиссия рәисе урынбасары: ________________________________

Комиссия әгъзалары:

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

Әзерлекне тикшерү акты белән танышмын, актның бер нөсхәсен алдым:
«___»______________ 20__ел          ___________________________________

Комиссиянең әзерлек таләпләрен үтәүгә карата шелтәләре булган яки актка әзерлек таләпләрен үтәмәгән очракта, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, шелтәләр исемлеге кушып бирелә.

Зеленодольск муниципаль районы

Башкарма комитеты

2017 елның 24 июнендәге

1802 номерлы карарының

1 нче кушымтасына

2 нче кушымтасы

# 2017/2018 елгы ягып җылыту чорына әзерлек ПАСПОРТЫ

______________________________________________________________бирелгән,
(җылыту сезонына әзерлекне тикшерү үткәрелгән муниципаль берәмлекнең, җылылык белән тәэмин итүче оешманың, җылылык челтәре оешмасының, җылылык энергиясен кулланучының тулы исеме)

Ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү үткәрелгән түбәндәге объектларга карата:
1.________________________;
2.________________________;
3.________________________;

Ягып җылыту чорына әзерлек паспортын бирү нигезләре:
Ягып җылыту  чорына әзерлекне тикшерү акты__________ N_________.

________________________/______________________
(имза, имзаны расшифровкалау һәм ягып җылыту чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия төзегән вәкаләтле орган мөһере)

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 24 июнендәге
1802 номерлы карарының
1 нче кушымтасына
3нче кушымта

**Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары өчен ягып җылыту чорына әзерлек буенча таләпләр**

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының ягып җылыту чорына әзерлеген бәяләү максатларында комиссия тарафыннан әлеге оешмаларда түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:

1) җылылык белән тәэмин итү турында Законда билгеләнгән тәртиптә җылылык белән тәэмин итү системасы белән идарә итү турында килешү булуын;

2) җылылык белән тәэмин итү схемасы белән расланган җылылык нагрузкалары графигын үтәүгә, температура графигын саклауга әзерлекне;

3) техник регламентларда билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы критерийларын үтәүне;

4) җылылык энергиясе чыганакларында норматив ягулык запаслары булуны;

5) эксплуатация һәм авария хезмәтләре эшчәнлеген, аерым алганда:

– күрсәтелгән хезмәтләрнең персонал белән комплектлануын;

– персоналны шәхси һәм коллектив саклану чаралары, махсус киемнәр, эшләр башкару өчен кирәкле инструментлар, норматив-техник һәм оператив документлар, инструкцияләр, схемалар, беренчел янгын сүндерү чаралары белән тәэмин ителешен;

6) үзләренең җылылык челтәрләрен җайга салуны;

7) җылылык энергиясен куллану режимнарын контрольдә тотуны оештыруны;

8) җылылык белән тәэмин иткечнең (теплоноситель) сыйфатын тәэмин итүне;

9) сатып алына һәм сатыла торган җылылык энергиясенең коммерция учетын оештыруны;

10) җылылык белән тәэмин итү объектларының авариясез эшен һәм җылылык энергиясен кулланучыларны ышанычлы рәвештә җылылык белән тәэмин итүне, ә аерым алганда:

– ягулык кабул итү һәм бушату, ягулык әзерләү һәм ягулык бирү системаларының әзерлеген;

– су-химия режимын үтәүне;

– җылылык энергетикасы җиһазларын эксплуатацияләү вакытын озайту буенча тиешле оештыру техник чараларын үткәрмичә, ресурстан тыш аларны эксплуатацияләү фактларының булмавын;

– торак йортларны җылылык белән тәэмин итү буенча авария хәлендәге җитешсезлекләрне бетерү өчен рөхсәт ителгән вакыт исәбе булуны;

– җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт

оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибенең булуын;

– җылылык челтәрләренә гидравлик һәм җылылык сынаулары үткәрүне;

– җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җиһазларны тиешле техник тикшерү һәм диагностикалау үткәрү кертелгән җылылык чорында эшләргә әзерлекнең расланган планын үтәүне;

– җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлау буенча план графигын үтәүне;

– ягулык белән тәэмин итү килешүләренең ягулык запасларының билгеләнгән нормативларын киметүгә юл куймый торган булуын;

11) җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатация җаваплылыгын чикләүне билгели торган документлар булуны;

12) дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен бирелгән җылылык чорында эшнең ышанычлылыгына йогынты ясый торган билгеләнгән срокларда үтәлмәгән күрсәтмәләрнең булмавын;

13) автоматик регуляторлар булганда, аларның эшләве.

Җылылык һәм электр энергиясен җитештерү объектларына карата катнаш эшләп чыгару режимында электр энергетикасы турындагы законнар нигезендә алынган җылылык сезонына әзерлек турында документ булу гына тикшерелә.

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларына карата шелтәләрне бетерү срокларын күрсәтеп, Исемлек белән акт төзелә торган шартларга әлеге 3 нче кушымтаның 1, 7, 9 һәм 10 пунктчаларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 24 июнендәге
1802 номерлы карарының
1нче кушымтасына
4 нче кушымта

**Җылылык энергиясен кулланучылар өчен ягып җылыту чорына әзерлек буенча таләпләр**

Җылылык энергиясен кулланучыларның ягып җылыту чорына әзерлеген бәяләү максатларында вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:
1) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җылылык һәм гидравлик эш режимнарында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү;
2) җылылык кулланучы җайланмаларның җиһазларын һәм коммуникацияләрен юдыру;
3) эксплуатация режимнарын, шулай ук аларны гамәлгә кертү чараларын эшләү;
4) ремонт эшләре планын үтәү һәм аларны үтәү сыйфаты;
5) җылылык энергиясен кулланучыга караган җылылык челтәрләренең торышы;
6) үзәк җылылык пунктларының, шулай ук индивидуаль җылылык пунктларының җылыту торышы (чормалар, баскыч клеткалары, подваллар, ишекләр) ;
7) җылылык пунктлары чикләрендә торба үткәргечләрнең, арматура һәм җылылык изоляциясенең торышы;
8) исәпкә алу приборларының булу һәм эшкә яраклыгы, алар булганда автомат җайга салучыларның эшкә яраклыгы;
9) җылылык куллану системаларын саклауның эшләве;
10) хезмәт күрсәтүче персонал өчен җылылык кулланучы җайланмаларның паспортлары, принципиаль схемалар һәм инструкцияләр булу һәм аларның дөреслеккә туры килүе;
11) суүткәргеч һәм канализация белән җылылык пунктлары җиһазларының турыдан-туры тоташкан булмавы;
12) җылылык пунктлары җиһазларының тыгызлыгы;
13) исәп алкаларында һәм элеваторларда пломбалар булу;
14) җылылык энергиясе (егәрлек) җылылык китерүче өчен бурычлар булмау ;
15) үзләренең һәм (яки) җәлеп ителгән ремонт бригадаларының булуы һәм җылылык куллану җайланмаларыннан тиешенчә файдалану өчен аларның матди-техник ресурслары белән тәэмин ителеше;
16) җылылык кулланучы җайланмаларның тыгызлыгына һәм ныклыгына сынау үткәрү;
17) критерийлар нигезендә климат шартларын исәпкә алып, җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 24 июнендәге
1802 номерлы карарына
2 нче кушымта

Коммуналь инфраструктура, социаль өлкә һәм торак фонды объектларының 2017/2018 елгы ягып җылыту сезонына әзерлеген тикшерү буенча комиссия составы

**Комиссия рәисе:**

Котельников Р.О. – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

**Комиссия рәисе урынбасары:**

Мәхмүтов И.А. – Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы киңәшчесе

**Комиссия секретаре:**

Анисимов О.В. – «ТР Зеленодольск муниципаль районы торак - коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе

**Комиссия әгъзалары:**

1. Афанасьева Р.В. – җитәкче урынбасары – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы
2. Шарифҗанова А.Р. – «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкчесе
3. Зиннуров Р.Н. – «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтү хезмәте» МУП директоры
4. Садыйков Р.Н. – Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы
5. Нуриев З.Д. – Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы
6. Ситдикова А.Р. – Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы
7. Валиуллин М.К. – Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы
8. Җиганшин И.А. – «Зеленодольск ПТС» ААҖ директоры (килешү буенча)
9. Кулькова Е.Н. –«Торак-коммуналь хезмәтләр» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)
10. Бәхтияров Р.Р. – «Норлат ТКХ МПП»МУП директоры (килешү буенча)
11. Гыйзатуллин Л.Р. – «Карамалы Тау торак-комсервисы» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)
12. Васев В.М. – «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча).